СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 10-27 «29» июнь 2018 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге № 4-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 14 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2018 елның 22 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2018 елның 30 мартындагы 197 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017 ел, №4-19 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.6 пунктның 12 абзацында «2018 елның 1 гыйнвары» сүзләрен «2020 елның 1 октябре» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 19.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.3. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына кертелә:

вазыйфаи оклад;

классслы чин өчен оклад;

муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.».

1.3. 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 23.15 пунктына өстәргә:

«23.15. Муниципаль хезмәткәргә ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне куллану турында белешмәләр җирле үзидарә органы тарафыннан, «коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 15 статьясында каралган ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр Муниципаль хезмәт узган, эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә».

2. Әлеге карарның 1.2 пункты кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов